Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче Урал торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«13» ноябрь 2024 ел — № 15

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 13 ноябрендә узган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пункты территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылганнар гражданнардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?:

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалап алу, төзекләндерү (Урал торак пунктындагы зират территориясендәге коймаларны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урал торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Урал торак пунктында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)) соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«РИЗА» — «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 129 граждан кертелде;

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 68 кеше, бу 52,7% тәшкил итә.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Риза» позициясе өчен 68 граждан тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын узган һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пункты территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылганнар гражданнардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?:

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалап алу, төзекләндерү (Урал торак пунктындагы зират территориясендәге коймаларны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урал торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Урал торак пунктында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)) - соравы буенча гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев